ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«27» август 2026 ел                № 714

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының "Арча муниципаль районының муниципаль милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура тәэи торган муниципаль оешма тарафыннан балалар өчен аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы муниципаль оешмаларын үзгәртеп оештыру яки бетерү хакында" 2026 елның 15 гыйнварындагы 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 9 августындагы "Татарстан Республикасы Дәүләт милке һәм (яисә) муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган Татарстан Республикасы Дәүләт оешмасы, муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү хакында" 775 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 26 июнендәге 753 номерлы карары нигезендә, Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районының муниципаль милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура

төзи торган муниципаль оешма тарафыннан аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура барлыкка китерә торган муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының “Арча муниципаль районының муниципаль милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү яисә бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура төзи торган муниципаль оешма тарафыннан балалар өчен аренда шартнамәсе, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсе төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы муниципаль оешмаларын үзгәртеп оештыру яки бетерү хакында” 2026 елның 15 гыйнварындагы 8 номерлы карары белән расланган бәяләмәләрне әлеге комиссия тарафыннан әзерләү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Тәртипнең 8 пунктындагы б пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) аңлатмалар, консультацияләр, мәгълүмат, бәяләмәләр һәм башка белешмәләр алу өчен комиссия утырышына вазыйфаи затларны чакырырга, экспертларны һәм (яисә) эшчәнлекнең төрле өлкәләрендәге белгечләрне җәлеп итәргә;»;

2) Тәртипнең 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле в һәм г пунктчалары өстәргә::

«в) карала торган мәсьәләләр буенча карар кабул итү өчен кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга һәм аларны тапшыру срокларын билгеләргә;

г) балалар өчен социаль инфраструктура объектларына барып аларны тикшерергә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (http://www.arsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. Г. Шәймәрдановага йөкләргә.

Җитәкче Л.И.Абдуллин